КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1253

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт буенча муниципаль оешмалар, яшьләр сәясәте өлкәсендәге хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» 2022 ел, 4 июль, 620 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт буенча муниципаль оешмалар, яшьләр сәясәте өлкәсендәге хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» 2022 ел, 4 июль, 620 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. Шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибе гамәлен Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләргә кагыла дип белдерергә.»;

3 пунктның өченче абзацында «пенсионер хезмәткәрләрне» сүзеннән соң «һәм Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрне» сүзләрен өстәргә;

4 пунктта «хезмәткәрләрне» сүзеннән соң «һәм Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрне» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган 2022 елда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең, Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү, физик культура һәм спорт буенча муниципаль оешмалар, яшьләр сәясәте өлкәсендәге хезмәткәрләрнең шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибенең 2.1 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бән итәргә:

«2.1. Шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗ хезмәткәр, түбәндәге документларны теркәп, бу Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән формада тутырылган гариза белән яшәү урыны буенча яисә хезмәткәрнең Татарстан Республикасында яшәү урыны булмаганда – эш (муниципаль хезмәт) урыны буенча территориаль социаль яклау органына мөрәҗәгать итә:».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү эшен 2022 елда Татарстан Республикасы территориясендә шифаханә-курорт дәвалавын гамәлгә ашыручы һәм Россия Федерациясе курорт фондының дәүләт реестрына кертелгән шифаханә-курорт оешмасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән түләүгә (өлешчә түләүгә) сертификатлар бирү юлы белән оештырырга;

бу карарны Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына җиткерергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин